# Проект эше «Минем яраткан уенчыгым» икенче кечкенәләр төркеме.



# Тема: «Уенчыклар».

*Яше:* 3-4 яшь

*Проект тибы: кыска вакытлы.*

## **Төзүче :**

*Казан шәһәре 402 нче номерлы балалар бакчасы тәрбиячесе Шәймәтова Рәмзия Габделфәртовна*



# Проектның максаты:

***Танып белү, уен эшчәнлекләре аша балаларда социаль- әхлакый сыйфатлар формалаштыру.***

# Бурычлар:

***Яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып , балаларның уен, танып белү , сөйләм, сенсорика күнекмәләрен үстерүне дәвам итү. Уенчыкларга карата эмоционально-эстетик һәм сак караш формалаштыру.***





***Үткәрелгән мероприятияләр:***



1. «**Уенчыклар нигә кирәк?** (Зачем нуңны игрушки?)», «**Күп төрле уенчыклар** (Такие разные игрушки)» темаларына әти-әниләр өчен консультацияләр.
2. «Минем яраткан уенчыгым» темасына балалар белән әңгәмә.
3. Китаплар һәм уенчык рәсемнәре төшерелгән иллюстрацияләр карау.




# 2. Уенчыклар темасына шигырьләр өйрәнү.

Курчакларым, килегез,
Яңа йортны күрегез.
Менә бусы – ишеге,
Рәхим итеп керегез!
(“Сүз тыңлаучан булыгыз” Резеда Вәлиева)

Песи, песи, пескәем,
Соры синең төскәең.
Йомшак синең йоннарың,
Җылы синең туннарың.
(«Мияу!»
Роберт Миңнуллин)







Әминә елый үкереп,
— Тубым суга төште, —
дип.
— Чү, Әминә, елама:
Туп батмый ул елгада.
(«Туп» Әминә
Бикчәнтәева)

Туп, туп, тубыбыз,
Син безнең матурыбыз,
Тишмәбез дә ярмабыз да,
Оста тота кулыбыз.
(“Туп, туп , тубыбыз”
Әминә Бикчәнтәева)





# 3. Уен ситуацияләре



**1.«Әйдәгез танышабыз».**

Курчак балаларга кунакка килә, исәнләшә, таныша. Исәнмесез?», «Хәерле иртә!» , «Мин - …» сүзләр тезмәсе кабатлатыла.

(Курчакларга исемнәр кушыла.)

-Мин сезгә уенчыклар алып килдем.

Балалар уенчыкларның ничек аталганын әйтәләр.

**2. «Кайсы уенчык юк?»** Балалар югалган уенчыкның атамасын дөрес итеп әйтергә тиеш. (Аю юк. Куян юк. һ. б.)

3. **«Һәр уенчыкның үз урыны».** Эшчәнлек барышыннан соң балалар уенчыкларны урыннарына куялар.

# 2. «Нәрсә үзгәрде? » уены









- Карагыз әле, бу нәрсә?
- Бу аю (курчак, машина һ.б.), - дип җавап бирергә кирәк. Балалар тарафыннан дөрес аталган уенчык өстәлгә куеп барыла. Уенчыкларны тезеп бетергәч, балалар күзләрен куллары белән каплыйларґґю шул вакытта тәрбияче бер уенчыкның урынын икенчесе белән алыштыра. Балалар кайсы уенчыкларның урыны үзгәргәнен белергә тиеш.

# 3. «Әйе- Юк» уены

Тәрбияче балаларга берәм- берәм уенчыклар күрсәтә һәм уенчык исемен ялгыш әйткән була. Балалар дөрес булмаса «юк» дип, дөрес булса - «әйе» дип, дөрес җавапны үзләре бирәләр.

(- Бу машина?

- Юк, бу курчак.)



# «Минем яраткан уенчыгым» проектының картасы

| **Белем бирү өлкәсе** | **Эшчәнлек төре** | **Эшчәнлек барышы** |
|---|---|---|
| Танып белү | Танып белү,<br>күзәтү аша танып белү | Уен ситуацияләре:<br>1.«Әйдәгез, танышабыз», «Кайсы уенчык юк?» уеннары;<br>2. «Нәрсә үзгәрде? » уены;<br>3. «Әйе-Юк» уены. |
| Физик үсеш | Уен, хәрәкәт | Хәрәкәтле уен «Ак куянкай утыра…» |
| Коммуникация | Коммуникатив | «Туп», «Сүз тыңлаучан булыгыз», «Мияу» шигырьләрен өйрәнү |
| Хезмәт | Хезмәт | «Һәр уенчыкның үз урыны» уен ситуациясе |
| Конструкцияләү | Уен, коммуникатив,<br>продуктив | Лего - конструкцияләү<br>1.«Уенчыкларны зурдан кечкенәгә тезү»;<br>2. «Бер рәткә тезү» |

## *Проекттан көтелгән нәтиҗәләр:*

Балаларның уенчыкларны татарча дөрес атаулары, татар телен өйрәнүгә кызыксынулары,уенчыклар белән кадерләп саклап уйнаулары, татарча сүзләр запасын баетлары. Әти-әниләрне татар теле белән кызыксындыру, «Минем яраткан уенчыгым» балалар рәсемнәре күргәзмәсе оешыру.





# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

